**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ**
**КОМИТЕТ**
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.07.2022 **Чирмешән авылы** №232

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының Торак сәясәте бүлеге тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең административ регламентларын яңа редакциядә раслау турында» 2018 елның 20 декабрендәге 590 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Урынны торак урыны, торак урыны яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле, бакча йортын торак йорты һәм торак йортны бакча йорты дип тану турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 6 апрелендәге 608 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының «Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының Торак сәясәте бүлеге тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын яңа редакциядә раслау турында» 2018 елның 20 декабрендәге 590 номерлы карары белән (район Башкарма комитетының 12.02.2021 ел, №69, 14.04.2021 ел, №175, 14.04.2021 ел, №178, 04.05.2021 ел, №205 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) расланган «Муниципаль торак фондыннан торак урынны яшәү өчен яраклы (яраксыз) дип һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип билгеләнгән тәртиптә тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты» 5 нче кушымтасына үзгәрешләр кертергә:

1.1. 1.5 пунктының 7 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Россия Федерациясе Торак кодексының 15 статьясындагы 6 өлешендә билгеләнгән билгеләргә туры килә торган бина күпфатирлы йорт дип таныла».

2. Әлеге карарны хокукый мәгълүматның рәсми порталында «pravo.tatarstan.ru» бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Район башкарма комитеты
җитәкчесе И.Н.Шәйдуллин